**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлегенең Әтрәкле торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

**2020 елның 09 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 10 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыенының йомгаклау беркетмәсе түбәндәге мәсьәлә буенча төзелде: "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Әтрәкле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә (1,2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш) үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?":

1) Әтрәкле торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);

2) Әтрәкле торак пунктында суэтем скважинасына тирәннән суырткыч насос сатып алу һәм урнаштыру;

3) Әтрәкле торак пунктында авыл паркы территориясен төзекләндерү (кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 202 халык җыенында катнашучы кертелгән, халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 111 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 111 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар бирде:

1. Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Әтрәкле торак пунктында халык җыены узуын танырга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Әтрәкле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә (1,2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш) үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?" мәсьәләсе буенча карарны танырга:

1) Әтрәкле торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);

2) Әтрәкле торак пунктында суэтем скважинасына тирәннән суырткыч насос сатып алу һәм урнаштыру;

3) Әтрәкле торак пунктында авыл паркы территориясен төзекләндерү (кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

3. Әтрәкле авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында

(https://menzelinsk.tatarstan.ru/atraklinskoye.htm) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә

**Халык җыенында рәислек итүче**
**Минзәлә муниципаль районы**
**Әтрәкле авыл җирлеге башлыгы**

**Р. Ш. Газизҗанов**